КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

___________________№_________________

На №_______________от_________________

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
И.Г. Һадиуллинга

Хөрмәтле Илсур Гәрәй улы!

«Салават күпере» – балалар өчен татар телендә нәшер ителә торган мультимедиа басма. Заман таләпләренә җавап биреп, 2020 елның июль санынnan «Салават күпере» журналы да форматын үзгәртте. Ул үзенчәлекле киселештә, яңа дизайнда дөнья күрә башлады. Журнал битләрендә үзенчәлекле QR кодлар урын алды. Телефонга бушлай йөкләтелә торган кушымта ярдәмендә бу кодлардан журналның YouTube каналына кереп була. YouTube

**«Бәби сүз»** проекты нәниләргә тәкъдим ителә. Ул балалар бакчаларында кулланыла торган уку-методик комплексы программасына нигезләнеп ясалган һәм бала үсеш дәверендә белергә тиешле сүзләрне үз эченә алган.

**«Беләсем килә»** сәхифәсендә баланы әйләндереп алган предметларга, хайваннар һәм кошлар, табигать күренешләренә, алар турындагы кызыклы фактларга багышланган видеолар тәкъдим ителә. «Салават күпере» журналының YouTube каналында дөнья күргән видеолар – сабыйлар өчен генә түгел, аларның әти-әниләре һәм тәрбиячеләре өчен дә уңайлы һәм файдалы әсбап.

**«Күңелле әлифба»** проектында Зөбәйдә исемле нәни кыз әтисе белән хәрефләр дөньясында сәяхәт итә. Алар югалган яисә качып киткән хәрефләрне коткарырга тиеш! Видеоларда һәр хәреф, анимацияләнгән, ул сөйләшә, елмая, күңелсезләнә ала. Әлеге проект хәрефләрне күңелле итеп өйрәнергә ярдәм итә.

Татар телен замана таләпләренә туры килгән форматта өйрәтү һәм камилләштерү максатыннан, әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына таратуыгызны сорыйбыз.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

Лист согласования к документу № 222и от 06.02.2021
Инициатор согласования: Казаченко Т.Е. Начальник общего отдела
Согласование инициировано: 05.02.2021 17:17

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Салимгараев А.С. | | Подписано 06.02.2021 - 10:33 | - |